КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 май г.Казань № 502

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Чүпрәле муниципаль районында «Рус Киштәге – Кошки-Новотимбаево» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында «Рус Киштәге – Кошки-Новотимбаево» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Кыят авыл җирлеге, «Кыят» дәүләт унитар предприятиесе адресы буенча урнашкан, дәүләт милкендә булган һәм «Киятское» ачык акционерлык җәмгыятенә (алга таба – арендага алучы) арендага тапшырылган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 71 219 369 кв.метр мәйданлы, 16:14:000000:154 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 85 841 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кыят авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәсен арендага алучыга, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, алына торган җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе туктатылу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны арендага алучыга җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге арендасы хокукы туктатылган өчен арендага алучыга акча түләүне;

арендага алучы тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында «Рус Киштәге – Кошки-Новотимбаево» автомобиль юлын төзү» линия объекты территорияләрен планлаштыру һәм межалау проектын раслау турында» 2021 елның 5 июлендәге 184/ик-п номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә һәм Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Кыят авыл җирлеге, «Киятское» дәүләт унитар предприятиесе адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 71 219 369 кв.метр мәйданлы, 16:14:000000:154 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин